**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Мокшы торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"07" ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Мокшы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Мокшы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Мокша авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Х. Ямашев урамы буенча Мокша авылы урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Мокшы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Мокшы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.